ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә (икенче өлеш), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.1 һәм 3.2 пунктлар өстәргә:

«3.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Түләнергә тиешле салым түләүче тарафыннан салым ташламасы суммасын билгеләгәндә салым түләүчене сайлау буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата салым ташламалары куллану өчен нигезләрнең санына карамастан бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) квартира, фатирның яисә бүлмәнең бер өлеше;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 бүлегендә күрсәтелгән бина яисә корылма;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 1 статьясындагы 1 пунктының 15 бүлегендә күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яисә корылмасы; 5) гараж яисә машина урыны.

Салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлардан һәм машина урыннарыннан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турындагы гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган сайланган объектлар турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына елның 1 ноябренә кадәр, шушы объектлардан башлап салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган салым органына тапшырыла.

Салым салуның сайланган объекты турында салым органына хәбәр иткән салым түләүче салым чоры булып торган елның 1 ноябреннән соң салым ташламасы бирелә торган салым салу объекты үзгәрүе белән төгәлләштерелгән хәбәрнамә тапшырырга хокуклы түгел.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче тарафыннан салым ташламасы сайланган объект турында хәбәр бирелмәгәндә, салым ташламасы салымның максималь исәпләнгән суммасы булган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш проспекты, 58 йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Юбилей урамы, ; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 56а йорт, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” урнаштырырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы физик затлар мөлкәтенә салымны 2019 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш авыл башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе Э.Н.Фаттахов